ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.03.2021 ел Баулы шәһәре №50

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль мөлкәт биргәндә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 25 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының – ярдәм алучыларның бердәм реестрын төзү максатларында үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 1 һәм 2 статьялары нигезендә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының – ярдәм алучыларның бердәм реестрын төзү максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль мөлкәт биргәндә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 25 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләр кертергә:

1 пунктның икенче һәм өченче абзацларында «кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау инфраструктурасын төзүче оешмаларга» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен һәм тыныш билгеләрен өстәргә;

4 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмалар» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар» сүзләрен һәм тыныш билгеләрен өстәргә;

5 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмалар» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар» сүзләрен һәм тыныш билгеләрен өстәргә;

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә каралган өченче затларның (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару кагыйдәләре» карарына кушымтада:

1 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга» сүзләреннән соң «индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен һәм тыныш билгеләрен өстәргә;

3 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмалар» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар» сүзләрен һәм тыныш билгеләрен өстәргә;

6 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмалар» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар» сүзләрен һәм тыныш билгеләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров